**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Лельвиж авыл җирлеге Советы**

# К А Р А Р

16 июнь, 2025 ел № 20

**Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Советы **карар кабул итте**:

1. Бишенче чакырылышТатарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Лельвиж авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.

2. 2. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча, «Хезмәт даны» газетасында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә, дип билгеләргә.

Җирлек башлыгы Э.Ю.Игнатьева

ОГРН 1061607753254
ИНН 1623003890